РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Аксубаевского муниципального
района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Аксубай муниципаль районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

« 04 » 05 2018

№ 224

Аксубаево

Башкарма комитетның архив бүлеге тарафыннан
муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ
регламентларын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 декабрендәге 880 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2013 елның 04 апрелендәге 111 номерлы карарына ярашлы рәвештә, түбәндәге **КАРАР БИРӘМ:**

1. Раславрга:

1.1. Архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документларының күчермәләре бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1 нче кушымта).

1.2. Муниципаль архивның уку залында эшләү өчен кулланучыга архив документларын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта).

1.3. Юридик затларга архивлар эшендә методик һәм практик ярдәм күрсәтү һәм эш башкаруда документлар оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (3 нче кушымта).

1.4. Архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (4 нче кушымта).

1.5. Ликвидацияләнә торган оешмаларның шәхси составы буенча документларны муниципаль архивка саклауга алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (5 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә http:/ Aksubayevo.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүмат порталында.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм мөлкәт белән идарә итү буенча беренче урынбасары И.И. Муратшинга йөкләргә.

Башкарма комитеты Җитәкчесе А.Ф. Горбунов